**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**IV чакырылыш чираттан тыш утырыш**
КАРАРЫ

2023 елның 15 декабре № 69 Уруссу ш.т.п.

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иҗтимагый советы турында Нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 17.02.2021 № 32 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иҗтимагый советы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының норматив хокукый актларын Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иҗтимагый советы турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 17 февралендәге 32 номерлы Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иҗтимагый советы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы Башлыгы указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, Ютазы муниципаль районы Уставына, Ютазы муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.»;

1.2. Нигезләмәнең 7.2 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган башка дәүләт оешмаларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары ачыкланган очракта, җәмәгать контролен гамәлгә ашыру барышында алынган материалларны, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан

Республикасы Башлыгы (Рәисе)  каршындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә  һәм прокуратура органнарына җибәрергә;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы  рәисе　　　　　　　　　　А.Ә.  Шәфигуллин